ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
21.09.2022

Иннополис шәһәре

КАРАР
70

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә гарантияле оешманы билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 7 февралендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә өзлексез су белән тәэмин итүне һәм су бүлеп бирүне тәэмин итү максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә гарантияләүче оешма статусын Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Озерная урамы, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан «ЗВКС» акционерлык җәмгыятенә бирергә.
2. «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын эксплуатацияләү буенча үз эшчәнлегендә «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 7 февралендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон белән җитәкчелек итәргә тиеш.
3. «ЗВКС» акционерлык җәмгыятенә абонентларны, шулай ук Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтырылган капиталь төзелеш объектларын законда билгеләнгән тәртиптә салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән тәэмин итәргә.

4. «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында» 2016 елның 09 декабрендәге 30 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны 7 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карарны «ЗВКС» Акционер җәмгыяте адресына җибәрергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы С.А. Беловага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Хуззәтов